Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль
районы Олы Салтык авыл җирлеге Советы
КАРАРЫ

18 май 2022 ел № 51

Татарстан Республикасы Кама Тамагы
муниципаль районы Олы Салтык авыл җирлеге
Советының 2016 елның 21 апрелендә кабул
ителгән 18 номерлы «Татарстан Республикасы
Кама Тамагы муниципаль районы Олы Салтык
авыл җирлегендә муниципаль вазыйфаларны
биләүгә дәгъва итүче гражданнар тарафыннан
керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы
йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук
Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль
районы Олы Салтык авыл җирлегендә муниципаль
вазыйфалар биләүче затлар тарафыннан керемнәр,
чыгымнартурында мөлкәте һәм мөлкәти
характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар
бирү турында " гы карарына
үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 1 апрелендәге 90-ФЗ номерлы Федераль закон, «Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Салтык авыл җирлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Салтык авыл җирлеге Советы КАРАР КЫЛДЫ:

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Салтык авыл җирлеге Советының 2016 елның 21 апрелендә кабул ителгән 18 номерлы «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Салтык авыл җирлегендә муниципаль вазыйфалар биләүгә дәгъва итүче гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Салтык авыл җирлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү турында " гы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 8 пунктның 3 пунктчасында «акцияләр» сүзен төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында игълан итәргә:

- ТР, Кама Тамагы районы, Олы Салтык авылы, Свердлов урамы, 126 йорт;
- ТР, Кама Тамагы районы, Олы Мәрәтхуҗа авылы, Ленин урамы, 61йорт;

- ТР, Кама Тамагы районы, Даныш авылы, Кооператив урамы, 71 йорт, шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга (kamskoye-ustye.tatarstan.ru).

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Салтык авыл җирлеге башлыгы Р.М. Вафинга йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Кама Тамагы муниципаль районы
Олы Салтык авыл җирлеге Башлыгы,
Татарстан Республикасы
Кама Тамагы муниципаль районы
Олы Салтык авыл җирлеге Советы рәисе Р.М. Вафин